КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 гыйнвар

г.Казань

№ 23

«Татарстан Республикасының Милли электрон китапханәсе» дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәне раслау хакында

«Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән «Татарстан Республикасының Милли электрон китапханәсе» дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәне расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

ТатарстанРеспубликасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 25 гыйнвар, 13 нче
карары белән расланды

«Татарстан Республикасының Милли электрон китапханәсе»
дәүләт мәгълүмат системасы турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Татарстан Республикасының Милли электрон китапханәсе» дәүләт әгълүмат системасын формалаштыру һәм эшләтү тәртибен, эшкәртелә торган мәгълүматтан файдалану кагыйдәләрен һәм тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

«Татарстан Республикасының Милли электрон китапханәсе» дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Система) – мәгълүмат җыю, аны эшкәртү, саклау һәм кулланучыларга бирүне тәэмин итә торган мәгълүмати ресурслар, сервислар һәм аппарат-программа чаралары җыелмасы тупланган бердәм мәгълүматлар базасы;

дәүләт заказчысы – Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният тармагын мәгълүматлаштыру өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүгә заказларны урнаштырганда Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы булып торучы вәкаләтле органы;

функциональ заказчы – системада мәгълүматларны (шул исәптән хезмәт алучы затларның (яки кулланучылар) персональ мәгълүматларын) эшкәртүне оештыра, барлык функциональ кулланучылар өчен оештыру-методик чараларны башлап җибәрә, шулай ук Системаның составын һәм гамәлләрен (операцияләрен), шул исәптән системада персональ мәгълүматлар белән эшләнә торган, контрольдә тота торган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы;

техник оператор – Системаны булдыру, үстерү һәм техник яктан тәэмин итү, Системада эшкәртелә торган мәгълүматны техник яклауны тәэмин итүче оешма;

координацион оператор – Системаның коррект контент тулылыгын тәэмин итү өлешендә координацияне тәэмин итүче оешма;

функциональ кулланучы – Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, эшчәнлек өлкәсендә эшли торган республика башкарма хакимият органы карамагындагы дәүләт оешмасы, Системаның функциональ заказчысы белән килештереп, Системадан файдалану мөмкинлеге бирелгән муниципаль оешма, шулай ук мәгълүматларны (шул исәптән хезмәт алучы затларның (яки кулланучылар) персональ мәгълүматларын) эшкәртүне гамәлгә ашыручы;

кулланучы – дәүләт һәм муниципаль һәркем өчен мөмкин булган китапханәләрдә, шул исәптән Системаның ачык өлешеннән мәгълүмат алу юлы белән дә, хезмәт алучы физик яки юридик зат;

Система операторы (-лары) – системаны эксплуатацияләү, шул исәптән мәгълүматлар базасында булган мәгълүматны эшкәртү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы дәүләт органнары, алар тарафыннан вәкаләтле бюджет учреждениеләре;

мәгълүматны эшкәртү – мәгълүматны җыю, системалаштыру, туплау, саклау, яңарту, үзгәртү, куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), мәгълүматны блоклау һәм юк итүне дә кертеп, мәгълүмат белән эш итү;

мәгълүмат алмашуда катнашучылар – функциональ заказчы, техник оператор, функциональ кулланучы, координацион оператор, алар алдында куелган бурычларны (функцияләрне) хәл итү максатларында система белән хезмәттәшлек итә торган;

Система объекты – әлеге Нигезләмәгә кушымтага ярашлы методика нигезендә система составына кертү өчен сайлап алынган басманың, электрон басманың, басылып чыкмаган документның, башка документның электрон рәвештәге күчермәсе.

1.3. Мәгълүмат алмашуда катнашучылар системаның эшләвен түбәндәге принципларны исәпкә алып тәэмин итәләр:

Россия Федерациясе законнары нигезендә мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем өчен мөмкин булуын;

кулланучыларга бирелә торган мәгълүматның дөреслеге һәм сыйфатын;

гражданнарның китапханә хезмәте күрсәтүгә хокукларын тәэмин итү максатларында мәгълүматны эшкәртү һәм аны электр элемтәсе челтәрләре аша тапшыру өчен заманча мәгълүмати технологияләр һәм техник чаралар куллануны;

авторларның һәм башка хокук ияләренең законлылыгы, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне;

мәгълүмат алмашуда катнашучы вазыйфаи затларның мәгълүматның тулылыгы һәм дөреслеге, аларны үз вакытында тапшыру һәм үзгәртү, шулай ук билгеләнгән тәртиптә саклау һәм юк итү өчен җаваплылыгын;

мәгълүматны бер тапкыр куллануга тапшыру һәм күп тапкыр куллануны;

Татарстан Республикасы китапханәләренең электрон формада китапханә ресурсларыннан үзара файдалануын;

Системаның башка мәгълүмат системалары һәм тышкы мәгълүмат ресурслары белән хезмәттәшлеген;

Системадагы мәгълүматны, шул исәптән рөхсәтсез керүдән саклау чараларын да кертеп, Россия Федерациясендә куллануга рөхсәт ителгән техник яклау чараларын куллану юлы белән яклауны.

## II. Системаның бурычлары, функцияләре, структурасы һәм аңа керү тәртибе

2.1. Системаның бурычлары булып тора:

Татарстан Республикасының бердәм мәгълүмати-китапханә киңлеген булдыру (дәүләт һәм муниципаль һәркем өчен мөмкин булган китапханәләр, белем бирү оешмалары китапханәләре);

Татарстан Республикасы халыкларының тарихи, фәнни һәм мәдәни байлыгын саклап калу;

милли мәдәниятнең басма һәйкәлләрен саклап калу һәм аларны киң җәмәгатьчелеккә таныту;

Татарстан Республикасы кулланучыларына китапханә фондларының составы турында мәгълүмат бирү;

китапханәләргә китапханә фондларын исәпкә алу системасын бирү;

дөрес мәгълүмат алу мөмкинлеген бирү юлы белән мәгълүмати-белем бирү мохитен формалаштыруга ярдәм итү;

Татарстан Республикасы территориясендә китапханәләрдән файдаланучыларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү процедурасын гадиләштерү;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә милли китап һәм телне популярлаштыру;

китапханә хезмәтләре күрсәтүнең сыйфат һәм сан күрсәткечләрен арттыру;

Татарстан Республикасының гамәлдәге электрон ресурслары белән интеграция;

мәдәниятара һәм милләтара хезмәттәшлекне үстерүгә ярдәм итү;

китапханәләргә программа-аппарат һәм методик ярдәм күрсәтүне тәэмин итү.

2.2. Система тәэмин итә:

Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә китапханәләрнең бердәм мәгълүмат базасын алып бару;

китапханә хезмәткәрләренең бердәм базасын алып бару;

китапханәдән файдаланучыларның бердәм базасын алып бару;

китапларны дистанцион броньга алу мөмкинлеге бирү;

китапханә фондын исәпкә алу һәм алга таба каталоглаштыру;

билгеләнгән вакытта китапларны кире кайтару буенча йөкләмәләрне үтәмәгән кулланучылар белән мониторинг һәм тиешле эш алып бару;

китапханә территориясендә үткәрелә торган иҗтимагый чаралар турында гражданнарга мәгълүмат бирү;

китапханә хезмәткәрләренең һөнәри эшчәнлеген методик тәэмин итү һәм аралашу өчен үзәкләштерелгән мәйданчык тәкъдим итү;

идарәчел карарлар кабул иткәндә аналитик һәм статистик мәгълүматны оператив тапшыру.

2.3. Система түбәндәге функциональ ярдәмче системалардан тора:

Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе порталы (kitap.tatar.ru);

«Профессионалларга» китапханә хезмәткәрләре өчен ярдәм бүлеге (help.kitap.tatar.ru);

«Эзләү һәм заказ» ярдәмче системасы;

«Каталогизация» ярдәмче системасы;

«Комплектлау» ярдәмче система;

«Китап бирү һәм китап укучылар белән идарә итү» ярдәмче системасы;

«Статистика» ярдәмче системасы;

«Электрон контент әзерләү» ярдәмче системасы;

«Администрацияләү» ярдәмче системасы;

«Интеграцион модуль» модуле;

«Бурычлар турында мәгълүмат бирү» модуле;

«Читтән китап кайтару» модуле;

«Массакүләм чараларга йөрүне исәпкә алу» модуле;

«Мониторинг» модуле.

2.4. Системага керү тәртибе үз эченә ала:

Система эшчәнлеген тәэмин итүгә кагылышлы өлешендә аларның бурычларын үтәү өчен оператор хезмәткәрләренә бирелә торган хезмәт мөмкинлеге;

кулланучыларга һәм алар тарафыннан теркәлү һәм (яки) аутентификация процедураларын узуга бәйле рәвештә бирелә торган кулланучыга бирелә торган, Системаның персонификацияләнгән параметрларын исәпкә алмыйча, мәгълүмат белән үзара бәйләнешне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән техник мөмкинлекләреннән ирекле файдалана алу мөмкинлеге, Системага керүне гамәлгә ашыручы затның персонификацияләнгән параметрларын исәпкә алып, Системаның техник мөмкинлекләренә авторизацияләнгән керү мөмкинлеге.

Күрсәтелгән параметрларны билгеләү зат тарафыннан Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе порталында авторизация процедурасын узу нәтиҗәләре буенча, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен электрон формада кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын, шулай ук «Татарстан Республикасы Электрон мәгарифе» дәүләт мәгълүмат системасын куллану юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.5. Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе порталына керү әлеге Нигезләмә нигезендә теркәлү һәм (яки) аутентификация процедураларын узмыйча гына бирелә. Кулланучыларны теркәү әлеге Нигезләмә нигезендә аларның теләге белән башкарыла.

## III. Мәгълүмат алмашуда катнашучыларның бурычлары һәм функцияләре

3.1. Система эше өчен җавап бирүче башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнарын һәм аларның карамагындагы учреждениеләрне билгеләү:

дәүләт заказчысы вазыйфаларын Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстер, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы башкара;

функциональ заказчы вазыйфаларын Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы башкара;

техник оператор вазыйфаларын «Татарстан Республикасы Мәгълүмат технологияләре үзәге « дәүләт унитар предприятиесе башкара;

координацион оператор вазыйфаларын «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе башкара;

функциональ кулланучы вазыйфаларын төрле дәрәҗәдәге дәүләт һәм муниципаль китапханәләр башкара.

3.2. Дәүләт заказчысы бурычлары һәм функцияләре:

Системаны үстерү һәм техник ярдәм күрсәтү буенча эшләрне башкару (хезмәтләр күрсәтү) өчен башкаручыларны билгеләнгән тәртиптә билгеләү;

Системаны үстерү һәм техник ярдәм күрсәтү буенча дәүләт контрактлары төзү;

Системаны үстерү һәм техник яктан ярдәм итү буенча чараларны бюджет акчалары исәбеннән финанслау.

3.3. Функциональ заказчының бурычлары һәм функцияләре:

Системаның мәгълүмат базасын тулыландыру буенча эшне координацияләүне тәэмин итү;

Система ярдәмче системаларын һәм модульләрен функциональ кулланучыларны, шулай ук Системага керү өчен исәп мәгълүматларын (логин һәм пароль) таратмауны контрольдә тоту;

Системаны камилләштергәндә координация операторы белән хезмәттәшлек итү;

Системаның аппарат-программа чараларын модернизацияләү, шулай ук Системаның функциональ мөмкинлекләрен камилләштерү буенча таләпләр һәм тәкъдимнәр формалаштыру;

Системада персональ мәгълүматларны дөрес эшкәртүне тәэмин итү буенча чаралар күрү.

3.4. Техник операторның бурычлары һәм функцияләре:

Системаның эшләвен тәэмин итә торган сервер һәм челтәр җиһазларының өзлексез эшләвен һәм Системаның функциональ ярдәмче системаларының өзлексез эшләвен тәэмин итү;

Системаны һәм функциональ кулланучыларны техник ярдәм белән тәэмин итү;

Системаның эшкә сәләтлелеген оптимальләштерүдә координация операторы белән хезмәттәшлек итү;

Системаның мәгълүматлар массивын һәм санлы коллекцияләрне саклауны оештыру;

Системада шәхси мәгълүматларны һәм мәгълүмат массивын саклаганда куркынычсызлыкның техник чараларын кабул итү;

Системаның аппарат-программа чараларының яңа версияләрен тестлау һәм җәелдерү;

Системада эшләгән вакытта барлыкка килгән өзеклекләрне бетерү;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт мәгълүмат системаларын булдыру, үстерү, кулланышка кертү, эксплуатацияләү һәм эксплуатацияләүдән чыгару һәм аларның базаларында булган мәгълүматларны алга таба саклау тәртибенә карата таләпләр турында» 6 июль, 2015 ел, № 676 карары белән расланган Дәүләт мәгълүмат системаларын булдыру, үстерү, кулланышка кертү, эксплуатацияләү һәм эксплуатацияләүдән чыгару һәм аларның базаларында булган мәгълүматларны алга таба саклау тәртибенә карата таләпләр нигезендә Системаның үсешен тәэмин итү.

3.5. Координация операторының бурычлары һәм функцияләре:

Система объектларын төзү, шул исәптән Система объектлары составына кертү өчен сайлап алынган документларны электрон формага күчерү буенча мәгълүмат алмашуында катнашучыларга консультация бирү;

функциональ кулланучыларның Система белән эшен координацияләү;

Системаның җыелма электрон китапханә каталогын үз фондларыннан алынган документларга библиографик язмалар белән даими тулыландыру;

Системаның җыелма электрон китапханә каталогы өчен функциональ файдаланучыларның язмаларын үз вакытында бирүләрен контрольдә тоту;

функциональ заказчы белән бергә Система эшләвен оптимальләштерү буенча тәкъдимнәр формалаштыруда катнашу;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Системаны алга этәрү.

3.6. Функциональ кулланучының бурычлары һәм функцияләре:

боеру акты нигезендә Системада эшләү өчен җаваплы хезмәткәрләрнең билгеләү;

Системаның мәгълүмат базасын, ярдәмче системаларын һәм модульләрен үз вакытында тутыру;

Системага кертелә торган мәгълүматның дөреслеген һәм актуальлеген тикшерү;

Системада эшкәртелә торган персональ мәгълүматларны чишү буенча чаралар күрү;

Системага керү өчен хисап мәгълүматларын (логин һәм пароль) таратмау буенча чаралар күрү;

авторлык хокукы белән саклана торган Система объектларының кулланучылар тарафыннан электрон күчермәләрен булдырмау буенча шартлар булдыру.

## IV. Кулланучыларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Система кулланучылары булып тора:

китапханәләр биналарында, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, керү мөмкинлеген гамәлгә ашыручы китапханәләр кулланучылары;

китапханәдән файдаланучылар булмаган һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Система объектларына ерактан торып керүне гамәлгә ашыручы физик затлар.

4.2. Система объектларына керүне гамәлгә ашыручы китапханәләр кулланучылары хокуклы:

керүгә:

Система объектлары буенча;

электрон коллекцияләр объектларының тулы текстларына (Системада катнашучы китапханәләр бинасында гына);

Системада катнашучы китапханәләр турында адреслы-белешмә мәгълүматка;

Татарстан Республикасы китапханәләре үткәрә торган чараларга (яңалыклар, вакыйгалар афишасы);

«Китапханәчедән сора» виртуаль белешмә хезмәтенә;

башка төр хезмәтләрдән, шул исәптән түләүле, файдаланырга.

4.3. Кулланучылар бурычлы:

Система функцияләвен бозуга юнәлдерелгән гамәлләр кылмаска;

әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләрне үтәргә;

Система объектларыннан файдаланганда авторлык хокукы һәм катнаш хокуклар турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләрне үтәргә.

## V. Система мәгълүматларына керү мөмкинлеген бирү, мәгълүматны саклауны тәэмин итү

5.1. Системага керү бурычларны бүлү һәм аутентификация һәм авторизация чараларын кулланып системаның эшләвен тәэмин итә торган вәкаләтләрне минимальләштерү принциплары нигезендә гамәлгә ашырылды.

5.2. Системаның мәгълүмат ресурсларында саклана торган шәхси мәгълүматлар аларны формалаштыру дәрәҗәсе һәм ысулларына бәйсез рәвештә, яшерен шартларда җыела, эшкәртелә, туплана, саклана һәм тапшырыла.

5.3. Системада персональ мәгълүматларны һәм башка конфиденциаль мәгълүматны эшкәртү федераль законнар нигезендә башкарыла.

«Татарстан Республикасының Милли электрон китапханәсе» дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәгә кушымта

«Татарстан Республикасының Милли электрон китапханәсе» дәүләт мәгълүмат системасы объектлары составына кертү өчен документларны сайлап алу методикасы

1. Әлеге Методика фәнни, белем бирү, мәдәни һәм тарихи кыйммәткә ия булган документларны сайлап алу критерийларын, шулай ук аларны «Татарстан Республикасының Милли электрон китапханәсе» дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Система) объектлары составына кертү кагыйдәләрен билгели.

2. Система объектлары составына кертү өчен документларны сайлап алу түбәндәге критерийлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

фәнни, мәгариф, мәдәни һәм тарихи кыйммәт;

шәхси үзенчәлекләренә ия булган басмаларның уникальлеге;

актуальлеген саклап калган һәм тулы кыйммәтле алмашка ия булмаган басманың тузуы;

гомуми һәм һөнәри белем бирү программаларында куллану.

3. Әлеге Методиканың 2 пунктында күрсәтелгән критерийларга туры килә торган документларны сайлап алу түбәндәге алымнарны исәпкә алып башкарыла:

фәнни һәм техник казанышларның актуальлеге, республика фәнен һәм мәдәниятен популярлаштыруга ярдәм итү;

Татарстан Республикасының күпмилләтле халкының тарихи, фәнни һәм мәдәни байлыгын саклап калу өчен әһәмиятле;

Татарстан Республикасы җәмгыять, фән һәм мәдәният үсешенә йогынты ясаган тарихи вакыйгалар белән үзара бәйләнештә.

4. Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе порталының «коллекцияләр» бүлегенә кертү һәм аларны цифрлаштыру алымнарына карата китапханә фондлары шартлы рәвештә ике категориягә бүленә:

I категория «Раритетлар»: китап һәйкәлләре (1830 елга кадәр), аеруча сирәк һәм кыйммәтле басмалар;

II категория «Нәфис-мәдәни кыйммәтләр һәм социаль әһәмияткә ия басмалар»: аерым сәнгать һәм мәдәни кыйммәтләре булган, автор иллюстрацияләре һәм рәсемнәре булган, шулай ук төбәк өчен зур социаль әһәмияткә ия басмалар.

5. Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе порталының «коллекцияләр» бүлегенә «Раритетлар» I категориядәге системалар беренче чираттагы цифрлаштырылырга һәм кертелергә тиеш:

1800 – 1928 еллар гарәп графикасында иске татар басма китаплары;

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар һәм көнчыгыш вакытлы басмалары;

1929 – 1939 еллар дәверендә латин графикасы (яңалиф) нигезендә татар телендә басмалар;

Татарстанның күренекле галимнәре, язучылары һәм җәмәгать эшлеклеләре

әсәрләренең беренче һәм исән вакытта чыккан басмалары.

6. Беренче чиратта цифрланырга һәм Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе порталының «коллекцияләр» бүлегенә «Сәнгать-мәдәни кыйммәтләр һәм социаль әһәмияткә ия басмалар» дигән II категориядән кертү төбәк өчен сәнгать, тарихи-мәдәни кызыксыну уяткан басмалар булырга тиеш, алар арасында:

туган якны өйрәнү һәм милли документларның бердәм нөсхәләре;

күренекле рәссамнар тарафыннан иллюстрацияләнгән һәм (яки) рәсмиләштерелгән басмалар;

полиграфик башкару һәм (яки) артык осталыкның сирәк үрнәкләре;

аз тиражлы һәм кыйммәтле басмалар;

шәхси үзенчәлекләренә ия уникаль басмалар;

картографик һәм рәсем басмалар (альбомнар, атласлар, фотоальбомна);

Татарстан Республикасының мөһим тарихи вакыйгаларын һәм истәлекле даталарын чагылдыручы мемориаль басмалар;

мөһим тарихи-мәдәни объект үзлегенә ия булган коллекцион басмалар;

милли китапханә фондының аеруча сорау булген басмалары;

дөнья күргән беренче елдан башлап республиканың (шәһәр, район) җирле вакытлы басмалары;

укучылар өчен актуальлеген саклап калган һәм тулы кыйммәтле алмашка ия булмаган тузган басмалар.

7. Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе порталының «коллекцияләр» бүлегенә, әһәмияте буенча, беренче чиратта цифрлаштыру һәм кертелүгә тигез булган документлардан системалар канәгатьләнмәслек физик хәлдә булган һәм интенсив кулланыла торган басмалар булырга тиеш.